| БАВЛИНСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

| РЕШЕНИЕ | КАРАР |
|---|---|
| 08.11.2024 ел | №144 |

Баулы шәһәр Советының
«Җир салымы турында»
2020 елның 23 октябрендәге
12 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче бүлекләренә, Россия Федерациясе аерым закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Баулы шәһәр Советы *КАРАР ИТТЕ*:

1. Баулы шәһәр Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 23 октябрендәге 12 номерлы карарына (Баулы шәһәр Советының 2020 елның 30 декабрендәге 20 номерлы, 2021 елның 14 декабрендәге 49 номерлы, 2023 елның 26 октябрендәге 112 номерлы, 2024 елның 13 июнендәге 129 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертергә:

2 пунктта 2 һәм 3 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) 0,3% торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлегенең өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләре, әлеге абзацта күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләреннән һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләреннән тыш;

3) һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән, әлеге абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш, 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып баруы турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»

Федераль законында каралган, шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук, гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата 0,3% ;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында pravo.tatarstan.ru һәм Баулы муниципаль районы сайтында bavly.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма алар рәсми басылып чыккан көннән кимендә бер ай узгач һәм чираттагы салым чорының 1 числосыннан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

Баулы шәһәре мэры урынбасары,
Шәһәр Советы Рәисе урынбасары К.Ф. Корбанов